**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 19 март № 169

г. Казань

Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын билгеләү турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 ел, 25 июнь, ФЗ-73 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 ел, 1 апрель, ТРЗ-60 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын һәм махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен;

Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимын.

2. Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрында теркәү өчен документларны 2015 елның 10 апреленә кадәр Россия Федерациясенең Мәдәният министрлыгына кертергә.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына үз компетенциясе чикләрендә мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендәге

җирләрдән файдалану режимы үтәлешен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.


Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\169.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 19 март, 169 нчы
карары белән расланды

**Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләре**

**1.** Яр Чаллы шәһәре, Боровецкое авылы, Чулман проспекты, 127 нче йорт (Брежнев шәһәре[*]) адресы буенча урнашкан «Вознесение чиркәве бинасы, 1872 – 1882 елларда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картасы (схемасы)**




Шартлы билгеләр:

– мәдәни мирас объекты

– мәдәни мирас объекты территориясе

[*] Мәдәни мирас объекты урнашкан урын аны дәүләт саклавына кую турындагы дәүләт хакимияте органы акты (ТАССР Министрлар Советының 1985 ел, 18 апрель, 229 нчы карары) нигезендә.

Яр Чаллы шәһәре, Боровецкое авылы, Чулман проспекты, 127 нче йорт (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Вознесение чиркәве бинасы, 1872 – 1882 елларда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Яр Чаллы шәһәре, Боровецкое авылы, Чулман проспекты, 127 нче йорт (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Вознесение чиркәве бинасы, 1872 – 1882 елларда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

төньяк-көнчыгыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (1-2 нче борылыш нокталары);

көньяк-көнчыгыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (2-3-4-5-6-7-8 нче борылыш нокталары);


көньяк-көнбатыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (8-9 нчы борылыш нокталары);

төньяк -көнбатыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (9-10-11-12-13-1 нче борылыш нокталары).

Яр Чаллы шәһәре, Боровецкое авылы, Чулман проспекты, 127 нче йорт (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Вознесение чиркәве бинасы, 1872 – 1882 елларда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокта-ның тәртип саны | Ноктаның МСК-16 системасындагы координатлары | | Ноктаның WGS-84 системасындагы координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | төньяк киңлек | көнчыгыш озынлык |
| 1 | 474233,136 | 2324746,988 | 55° 46' 29.65" | 52° 25' 33.87" |
| 2 | 474210,030 | 2324784,210 | 55° 46' 28.89" | 52° 25' 36.00" |
| 3 | 474200,661 | 2324776,541 | 55° 46' 28.59" | 52° 25' 35.55" |
| 4 | 474176,577 | 2324780,939 | 55° 46' 27.81" | 52° 25' 35.80" |
| 5 | 474152,215 | 2324764,865 | 55° 46' 27.03" | 52° 25' 34.87" |
| 6 | 474144,627 | 2324756,314 | 55° 46' 26.78" | 52° 25' 34.37" |
| 7 | 474086,233 | 2324699,327 | 55° 46' 24.91" | 52° 25' 31.09" |
| 8 | 474059,894 | 2324668,244 | 55° 46' 24.06" | 52° 25' 29.30" |
| 9 | 474097,870 | 2324637,691 | 55° 46' 25.29" | 52° 25' 27.55" |
| 10 | 474125,813 | 2324654,441 | 55° 46' 26.19" | 52° 25' 28.52" |
| 11 | 474177,903 | 2324711,168 | 55° 46' 27.87" | 52° 25' 31.80" |
| 12 | 474179,436 | 2324710,231 | 55° 46' 27.92" | 52° 25' 31.74" |
| 13 | 474190,183 | 2324723,176 | 55° 46' 28.26" | 52° 25' 32.49" |

**2.** Яр Чаллы шәһәре, Орловка поселогы, Яр Чаллы проспекты (Брежнев шәһәре*) адресы буенча урнашкан «Косьма һәм Дамиан чиркәве бинасы, 1844 елда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картасы (схемасы)**




Шартлы билгеләр:

– мәдәни мирас объекты

– мәдәни мирас объекты территориясе

* Мәдәни мирас объекты урнашкан урын аны дәүләт саклавына кую турындагы дәүләт хакимияте органы акты (ТАССР Министрлар Советының 1985 ел, 18 апрель, 229 нчы карары) нигезендә.

Яр Чаллы шәһәре, Орловка поселогы, Яр Чаллы проспекты (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Косьма һәм Дамиан чиркәве бинасы, 1844 елда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картографик тасвирламасы**

Яр Чаллы шәһәре, Орловка поселогы, Яр Чаллы проспекты (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Косьма һәм Дамиан чиркәве бинасы, 1844 елда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре түбәндәгечә үтә:

төньяк-көнчыгыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (1-2-3-4-5-6-7-8-9-10 нчы борылыш нокталары);

көньяк-көнчыгыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (10-11-12-13-14 нче борылыш нокталары);

көнбатыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (14-15-16-17 нче борылыш нокталары);

төньяк -көнбатыш өлеше: кирпеч нигездәге металл койма буеннан (17-18-19-20-21-22-23-1 нче борылыш нокталары).

Яр Чаллы шәһәре, Орловка поселогы, Яр Чаллы проспекты (Брежнев шәһәре) адресы буенча урнашкан «Косьма һәм Дамиан чиркәве бинасы, 1844 елда төзелгән» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокта-ның тәртип саны | Ноктаның МСК-16 системасындагы координатлары | | Ноктаның WGS-84 системасындагы координатлары | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | төньяк киңлек | көнчыгыш озынлык |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | 467463,936 | 2321142,150 | 55° 42' 51.39" | 52° 22' 5.20" |
| 2 | 467460,648 | 2321143,416 | 55° 42' 51.28" | 52° 22' 5.27" |
| 3 | 467461,648 | 2321146,011 | 55° 42' 51.31" | 52° 22' 5.42" |
| 4 | 467420,229 | 2321163,930 | 55° 42' 49.97" | 52° 22' 6.44" |
| 5 | 467416,311 | 2321155,096 | 55° 42' 49.84" | 52° 22' 5.93" |
| 6 | 467391,122 | 2321160,966 | 55° 42' 49.03" | 52° 22' 6.26" |
| 7 | 467389,150 | 2321153,308 | 55° 42' 48.97" | 52° 22' 5.82" |
| 8 | 467378,685 | 2321150,031 | 55° 42' 48.63" | 52° 22' 5.63" |
| 9 | 467368,022 | 2321153,465 | 55° 42' 48.28" | 52° 22' 5.82" |
| 10 | 467347,016 | 2321157,711 | 55° 42' 47.60" | 52° 22' 6.06" |
| 11 | 467324,615 | 2321101,352 | 55° 42' 46.89" | 52° 22' 2.83" |
| 12 | 467330,219 | 2321087,792 | 55° 42' 47.07" | 52° 22' 2.05" |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 13 | 467313,846 | 2321051,068 | 55° 42' 46.55" | 52° 21' 59.94" |
| 14 | 467315,813 | 2321047,664 | 55° 42' 46.61" | 52° 21' 59.75" |
| 15 | 467337,879 | 2321049,730 | 55° 42' 47.32" | 52° 21' 59.87" |
| 16 | 467354,174 | 2321051,958 | 55° 42' 47.85" | 52° 22' 0.01" |
| 17 | 467397,407 | 2321058,722 | 55° 42' 49.25" | 52° 22' 0.41" |
| 18 | 467410,578 | 2321064,034 | 55° 42' 49.67" | 52° 22' 0.71" |
| 19 | 467417,310 | 2321067,716 | 55° 42' 49.89" | 52° 22' 0.93" |
| 20 | 467425,761 | 2321074,369 | 55° 42' 50.16" | 52° 22' 1.31" |
| 21 | 467430,872 | 2321079,587 | 55° 42' 50.33" | 52° 22' 1.61" |
| 22 | 467441,607 | 2321093,071 | 55° 42' 50.67" | 52° 22' 2.39" |
| 23 | 467447,820 | 2321102,007 | 55° 42' 50.87" | 52° 22' 2.90" |

F:\KARAR\2015\169-1.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 19 март, 169 нчы
карары белән расланды

**Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимы**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 март, 169 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

мәдәни мирас объектларын ремонтлау, консервацияләү һәм реставрацияләү;

мәдәни мирас объектларының бөтенлеген бозмый һәм аларның бозылу, җимерелү яки юкка чыгу куркынычын тудырмый торган хуҗалык эшчәнлеге;

саклау предметын тәшкил итүче үзенчәлекләрен үзгәртмичә функциональ файдаланырга рөхсәт ителгән төрләре нигезендә мәдәни мирас объектларын заманча файдалану өчен яраклаштыру;

мемориал һәм архитектура ансамбле буларак әһәмияткә ия булган югалган тарихи элементларын фәнни нигездә элекке хәленә кайтару - регенерацияләү;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган вакытлыча корылмаларны һәм объектларны бетерү;

ядкәр территориясендә урнашкан, тарихи-шәһәр төзелеше, пространство-архитектура ягыннан һәм мемориал буларак зур әһәмияткә ия булмаган биналарның кыйммәтле элементларын консервацияләп һәм фасадларын реставрацияләп, мөмкин булганча техник модернизацияләп реконструкцияләү;

булган объектларның инженерлык инфраструктурасын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләрне) капиталь ремонтлау;

төзекләндерү – мәйданчыкларны, якын килү һәм транспорт узу урыннарын каплауда традицион материаллардан (таштан, граниттан һәм табигый булып күренә торган башка материаллардан) файдалану; тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирүче аерым тора торган яктырту җайланмасыннан файдалану;

яшелләндерү – агачларның кыйммәтле төрләрен саклау;

мәдәни мирас объектының беренче катыннан югары булмаган биеклектә мәдәни мирас объектлары фасадларында мәгълүмати язулар һәм билгеләр, мемориаль такталар кую;

оешмаларның элмә такталарын кую.

Югарыда билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләренең биеклеге чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган катларның тәрәзәләре арасындагы аралык, фриз биеклегенең 2/3 өлешеннән артмаска тиеш, моңа

декоратив-сәнгать паннолары керми. Аркалы тәрәзәләр булганда катларның тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге 1/2 гә кадәр киметелә.

Мәгълүмат конструкцияләренең киңлеге, чикләрендә теге яки бу конструкцияне урнаштыру регламентлана торган аралык киңлегенең 2/3 нән артмаска тиеш.

Югарыда күрсәтелгән барлык эшләр Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә һәм тәртибендә үткәрелә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 март, 169 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрендә түбәндәгеләр тыела:

капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен урнаштыру, шулай ук җир төзелеше эшләрен, җир, төзелеш, хуҗалык эшләрен һәм мәдәни мирас объектларын саклауга бәйле булмаган башка эшләрне проектлау, үткәрү;

мәдәни мирас объектлары фасадында һәм түбәсендә кондиционерлар, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

җир өсте ысулы белән инженерлык инфраструктурасы объектларын (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон кертү буенча тышкы челтәрләр) үткәрү;

киосклар, павильоннар, өслекләр; кече архитектура формалары кую, югалганнарын торгызудан тыш;

агачның кыйммәтле төрләрен кисү, санитария максатында кисүдән башка.

---